Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм дәүләт һәм муниципаль архивларда, музейларда һәм китапханәләрдә, Россия Фәннәр академиясе оешмаларында башка архив документларын саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм алардан файдалануны оештыруның Россия Федерациясе Мәдәният һәм масакүләм коммуникацияләр министрлыгының 18.01.2007 № 19 боерыгы белән расланган кагыйдәләре белән (алга таба – Кагыйдәләр) (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 14.05.2007, №20, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы (алга таба – № 45-ТРЗ ТР Законы) (Ватаным Татарстан, 2004, 3 август, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына бирү турында» 2007 елның 24 декабрендәге № 63-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 2007 елгы № 63-ТРЗ Законы) (Ватаным Татарстан, 2007, 25 декабрь, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге № 63-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 2017 елгы № 63-ТРЗ) («Татарстан Республикасы законнары җыелмасы», 25.07.2017, Т 55 (I өлеш), ст. 2016);

«Муниципаль берәмлекләр барлыкка килгәнче, кушылганчы, бүленгәнче яисә аның статусы үзгәргәнче булдырылган һәм Татарстан Республикасы муниципаль

архивларында сакланучы архив документларына милекчелекне чикләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.05.2007 № 203 карары (алга таба – ТРМК № 203 карары) (Ватаным Татарстан, 2007, 25 декабрь, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

___ ____ 200_ расланган ______________муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав);

____________________муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турындагы нигезләмә) белән;

муниципаль берәмлек Башкарма комитетының архив бүлеге турында Башкарма комитетның ________ № __ карары белән расланган нигезләмә (алга таба – Бүлек турында нигезләмә) белән;

20_ _____________ ___№_ расланган Эчке эш тәртибе кагыйдәләре белән (алга таба – Эчке эш тәртибе кагыйдәләре)»;

1.5 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән белешмәләрнең (дәүләт хезмәт күрсәтүе нәтиҗәсе) белешмәләр кертү өчен нигез булган документлардагы белешмәләргә туры килмәвен китереп чыгаручы хата (дөрес язмау, дөрес басмау, грамматик яисә арифметик хата булу)»;

бишенче абзацта «http://uslugi.tatar.ru» сүзләрен «http://uslugi.tatarstan.ru» сүзләренә алмаштырырга.

2, 3 бүлекләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы һәм аның стандартына карата таләпләр | Стандартка карата таләпнең эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүен яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы | Архивның уку залында эшләү өчен архив документларын файдаланучыга бирү | № 125-ФЗ Федераль законның 24 ст. 1 өлеш;<br>2017 елгы № 63-ТРЗ ТР Законының 21 ст.;<br>2017 елгы № 63-ТРЗ ТР Законының 1 ст.;<br>Кагыйдәләрнең 5.7, 5.12, 5.13 п. |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче җирле үзидарә органы атамасы | _____________муниципаль районының Башкарма комитеты<br>Дәүләт хезмәтен башкаручы – Башкарма комитетның Архив бүлеге | № 125-ФЗ Федераль закон ның ст. 4 ст. 3 өлеш;<br>2017 елгы № 63-ТРЗ ТР Законының 7 ст.;<br>Бүлек турында нигезләмә |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы | Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм дәүләт серен тәшкил итмәгән башка архив документларын, Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән бүтән чикләүләрне исәпкә алып, һәм басма нәширлекләрнең фәнни-белешмә китапханәләрендә саклanучы аларга карата белешмә-эзләү чараларын муниципаль архивларның уку залларында (карап чыгу залларында, фонодокументларны тыңлап карау бүлмәләрендә, каталоглар бүлмәләрендә) яисә (махсус бүленгән урын булмаганда) архивның эш | № 125-ФЗ Федераль закон ның ст. 24 ст. 1 өлеш;<br>2017 елгы № 63-ТРЗ ТР Законының 22 ст.;<br>Кагыйдәләрнең 5.12, 5.13. пп.;<br>Тәртипнең 1.2, 3.1, 4.1.1, 4.1.3, 4.1.4, 4.1.5, 4.1.6, 4.1.7 пп. |

| | | |
|---|---|---|
| | бүлмәсендә (алга таба – уку залы) эшләү өчен файдаланучыларга архив хезмәткәре контролендә бирү | |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмага мөрәҗәгатьне исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы | эшләргә, документларга белешмә-эзләү чаралары алу, шулай ук уку залындагы автоматлаштырылган белешмә-эзләү чараларын алу мөмкинлеге – гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне;<br>эшләр, документлар алу (алу мөмкинлеге чикләнгән, сер булуы өлешчә туктатылган, чит телләрдәге документлардан гайре) – гариза бирүче заказын рәсмиләштерү көненнән 2 эш көнендә;<br>эшләр, документлар алу (алу мөмкинлеге чикләнгән, сер булуы өлешчә туктатылган, чит телләрдәге документлардан гвайре) – гариза бирүче заказын рәсмиләштерү көненнән 10 эш көнендә;<br>дәүләт хезмәт күрсәтүе срогын туктатып тору мөмкинлеге каралмаган | Тәртипнең 3.1 – 3.6, 4.1.7 пп. |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен законнар яисә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның, шулай ук дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен кирәкле һәм гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны гариза бирүче тарафыннан алу, шул исәптән электрон рәвештә дә, алымнары, | Шәхсән (язмача) кабул иткәндә граждан түбәндәгеләрне тапшыра:<br>1. Файдаланучыны архивка җибәргән орган яисә оешма хаты, яисә файдаланучы гаризасы, файдаланучының уку залында эшләү вакытын озайту турында гаризасы.<br>Шәхси гаризада яисә хатта файдаланучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булса), вазыйфасы (булса), гыйльми исеме һәм гыйльми дәрәҗәсе (булса), тикшеренү темасы һәм хронологик кысалары күрсәтелә. | Тәртипнең 2.1, 2.2, 2.4 пп. |

| | | |
|---|---|---|
| аларны бирү тәртибе | 2. Шәхесен таныклаучы документлар:<br>гариза бирүченең;<br>балигъ булмаган гариза бирүченең ата-анасының яисә башка законлы вәкиленең;<br>озата йөрүче затларының (в шул исәптән законлы вәкилләренең, тәрҗемәчеләренең һәм башка ярдәмчеләрнең, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән файдаланучыны озата йөрүче затларның).<br>3. Юридик зат вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документлар.<br>Гариза бирүче Башкарма комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын алырга мөмкин. Бланкларның электрон рәвешләре Башкарма комитетның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында урнаштырыла.<br>Гариза кәгазь саклагычларда түбәндәге алымнарның берсе белән гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән эш йөртүче зат тарафыннан ышанычнамә нигезендә);<br>заказлы почта юлламасы белән.<br>Гариза һәм документлар, шулай ук гариза бирүче тарафыннан гади электрон имза куеп, электрон документ рәвешендә, Башкарма комитетның «Интернет» гомуми файдаланудагы | |

| | | |
|---|---|---|
| | мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче алырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүче тарафыннан аларны алу методикалары, шул исәптән электрон рәвештә дә, аларны алу тәртибе; әлеге документлар үз карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы йә оешма атамасы | Бу категориягә каравы мөмкин булган документларны тапшыру таләп ителми | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актларда каралган очракларда, дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан килештерүе таләп ителә торган дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Тиешле зат тарафыннан документлар тапшыру.<br>2. Тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документлар исемлегенә туры килмәве.<br>3. Тапшырыла торган документларда алдан сөйләшенмәгән төзәтүләр булу | № 125-ФЗ Федераль законның 25 ст.;<br>2017 елгы № 63-ТРЗ ТР Законының 21 ст.;<br>Тәртипнең 2.1 п. |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Документлар тапшыру срогын туктатып тору каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1. документлардан файдалануга Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән яисә даими саклауга документлар тапшырганда фонд барлыкка китерүче тарафыннан билгеләнгән чикләүләр;<br>2. документларның физик халәте канәгатьләнмәслек булу;<br>3. балигъ булмаган гариза бирүченең ата-анасыннан яисә бүтән законлы вәкиленнән башка мөрәҗәгать итүе;<br>4. гариза бирүченең Тәртипнең 4.2.5, 4.2.6, 4.2.9, 4.2.12, 4.2.19 пунктчаларын бозуы;<br>5. файдалану фонды булмаган очракларда, түбәндәгеләрне башкарганда:<br>архив хезмәткәрләре тарафыннан файдаланучылар таләп иткән эшләрнең, документларның, басма нәширлекләрнең төп нөсхәләрен файдаланып, хезмәт биремнәрен үтәгәндә – файдаланучы аларга заказ биргән | № 125-ФЗ Федераль законның 26 ст., 8 өлеше;<br>№ 125-ФЗ Федераль законның 25 ст.;<br>2017 елгы № 63-ТРЗ ТР Законының 21 ст.;<br>Тәртипнең 2.2, 3.6, 3.7 пп.;<br>Кагыйдәләрнең 2.11.7.1, 2.11.10, 5.13 пп.;<br>Тәртипнең 3.2, 3.3, 3.4, 3.5, 3.6 пп. |

| | | |
|---|---|---|
| | көннән 120 эш көненнән дә артмаган срокта;<br>эшләрнең, документларның, басма нәширлекләрнең төп нөсхәләрен юридик затларга һәм физик затларга - фонд барлыкка китерүчеләргә, аларның хокукый варисларына яисә дәүләт хакимияте органнары һәм бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары гарызнамәләре буенча биргәндә – мондый эшләрне, документларны, басма нәширлекләрне вакытлыча файдалануга бирү турындагы актта күрсәтелгән сроктан артмаган срокта;<br>эшләрнең, документларның, басма нәширлекләрнең төп нөсхәләрен күргәзмәгә куйганда – архив саклагычтан аларны бирү буенча күргәзмә уздыруга күрсәтмә документта билгеләнгән сроктан артмаган срокта;<br>эшләрнең, документларның, басма нәширлекләрнең төп нөсхәләрен уку залында башка файдаланучыга биргәндә – аларга файдаланучы заказ биргән көннән 40 эш көненнән дә артмаган срокта | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яисә бүтән түләү тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләүнең күләмен исәпләп чыгару алымы турындагы мәгълүматны да кертеп | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | № 125-ФЗ Федераль законның 15 ст., 3 өлеше;<br>№ 125-ФЗ Федераль законның 8 ст., 1 өлеше;<br>Тәртипнең 4.1.1 п. |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри, дәүләт хезмәте күрсәтүләр өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, | Кирәкле һәм мәҗбүри дәүләт хезмәте күрсәтүләр таләп ителми | № 125-ФЗ Федераль законның 15 ст., 3 өлеше;<br>№ 125-ФЗ Федераль законның 8 ст., 1 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| мондый түләү күләмен исәпләп чыгару методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә биргәндә һәм мондый дәүләт хезмәте күрсәтүләр нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | Гарызнамә биргәндә һәм нәтиҗәсен алганда дәүләт хезмәте күрсәтелүчене (гариза бирүчене) кабул итүнең максималь срогы 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелүчеләрнең аерым категорияләре өчен чиратлылык билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүче гарызнамәсен теркәү срогы, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергән көнне. Электрон рәвештә, ял (бәйрәм) көнне кергән гарызнамә ял (бәйрәм) көненнән соңгы көндә теркәлә | Эшләр алып бару кагыйдәләренең IV өлешенең 16 п. |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләр көтә торган һәм аларны кабул итү урынына, шул исәптән әлеге объектларга инвалидлар кереп йөри алу мөмкинлеген инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматка карата таләпләр | Дәүләт хезмәтләренең янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җайланмалар белән, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм урыннарда күрсәтелүе.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына каршылыксыз кереп йөрүе тәэмин ителә (бинага керү урының җайлы булуы һәм бина буйлап йөрүләренең җайлы булуы).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән гариза | Дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкин булуы күрсәткечләре түбәндәгеләр:<br>документлар кабул итү, бирү урыннарының | № 125-ФЗ Федераль законның 24 ст., 1 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара аралашу саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтенең дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күп функцияле үзәкләрендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күп функцияле үзәгенең ерак урнашкан эш урыннарында күрсәтелү мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат- коммуникация технологияләрен кулланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге | ______________ җәмәгать транспорты йөрү зонасында урнашкан булуы;<br>кирәкле санда белгечләр булу, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү урыннарының кирәкле санда булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү алымнары, тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат стендларында, ________________ мәгълүмат ресурсларында, «Интернет» челтәрендә, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтүгә комачаулаучы каршылыкларда ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>гариза бирүчедән документлар кабул иткәндә һәм аңа документлар биргәндә чиратлар булмау;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары бозылулар булмау;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләр гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр булмау;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчелщргщ карата хәер-хаксыз мөнәсәбәтенә, игътибарсызлыгына шикаятьләр булмау.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә биргәндә һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи зат белән | |

| | | |
|---|---|---|
| | гариза бирүченең аралашуы бер мәртәбә була дип күзаллана. Аралашу дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә.<br>Дәүләт хезмәте КФҮ, КФҮнең ерак урнашкан эш урыннары аша күрсәтелми. дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә консультация бирү,<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турындагы мәгълүматны гариза бирүче Башкарма комитет сайтында, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү порталында һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәте күрсәтүләрнең бердәм порталында алырга мөмкин. | |
| 2.16. Элек-трон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап гариза электрон документ рәвешендә түбәндәге электрон адрес буенча җибәрелергә мөмкин:<br>Башкарма комитетның рәсми сайты (http://www.__________.tatar.ru;<br>Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/);<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru/) | № 59-ФЗ Федераль законның 19 ст., 1 өлеше |

## 3. Административ процедуралар составы, аларны үтәү эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күп функцияле үзәкләрендә, күп функцияле үзәкнең ерак урнашкан эш урыннарында үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеге тасвирламасы.

3.1.1. муниципаль архивның уку залында эшләү өчен архив документларын файдаланучыга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә түбәндәге процедуралар керә:

1) гариза бирүчегә консультацияләр бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) документларны тикшерү, анкета һәм персональ белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгын бирү һәм конфиденциальлек режимын үтәү турында йөкләмә-килешү бирү;

4) документларны, файдалану фонды күчермәләрен, описьларны бирүгә заказ (таләп) бланкын тутыру өчен гариза бирүчегә бирү;

5) муниципаль архивның уку залында эшләү өчен архив документларын ачыклау һәм файдаланучыга әзерләү;

6) муниципаль архивның уку залында эшләү өчен архив документларын файдаланучыга бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 2 нче кушымтада китерелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү.

3.2.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтелү тәртибе турында консультацияләр алу өчен Бүлеккә шәхсән, телефон аша һәм (яисә) язма рәвештә, шул исәптән электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелү өчен кирәкле документлар составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация бирә. Дәүләт хезмәте күрсәтүен китереп чыгаручы гарызнамә бирү документларны рәсмиләштерү өлешендә гариза бирүчегә ярдәм күрсәтүне таләп итми.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә консультация бирү.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гариза бирүче (аның вәкиле) шәхсән, кәгазь саклагычта, электрон рәвештә, Башкарма комитетның рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша йә почта аша почта юлламасы рәвешендә гариза бирә (җибәрә).

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон рәвештәге гариза электрон почта яисә Башкарма комитетның Интернет-кабул итүе аша җибәрелә. Электрон рәвештә кергән гариза бастырыла һәм билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

3.3.2. Гариза электрон рәвештә җибәрелгәндә Башкарма комитетның Интернет-кабул итүе аша кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү өчен

җаваплы белгече кергән гаризаны бастыра, терки һәм электрон рәвештә һәм кәгазьдә килеш Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән мизгелдән бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: теркәлгән һәм Бүлеккә җибәрелгән гариза яисә хат.

3.4. Муниципаль архивның уку залында эшләү өчен архив документларын файдаланучыга бирү.

3.4.1. Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гариза бирүче ышанычнамә буенча эш йөрткән очракта, гариза бирүче вәкаләтләрен тикшерә;

барлык кирәкле документлар булуны һәм аларның билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә (документларны тиешенчә рәсмиләштерүне, документларда чистартулар, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм аларда алдан сөйләшенмәгән бүтән төзәтүләр булу-булмауны).

Искәрмәләр булмаган очракта, Бүлек белгече гаризаны кабул итеп ала һәм терки.

Гариза беренче мәртәбә кергән очракта, гариза бирүчегә тутыру өчен билгеләнгән үрнәктәге анкета тапшыра (4 нче кушымта), балигъ булмаган гариза бирүченең ата-анасына яисә башка законлы вәкиленә, озата килүче затка (шул исәптән законлы вәкиленә, тәрҗемәчегә һәм башка ярдәмчеләренә, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән файдаланучыны озата йөрүче затларга) – анкета тапшыра, анда түбәндәгеләр күрсәтелә: фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булса), туган датасы, гражданлыгы, эш (уку) урыны һәм вазыйфасы (булса), яшәү (тору) урыны буенча теркәү адресы, фактта яшәү адресы, контакт телефонының номеры (булса), электрон почтасы адресы (булса), шәхесен таныклаучы документы төре, сериясе, номеры һәм датасы, шулай ук документны биргән орган, озата йөрүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булса), персональ белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгы һәм конфиденциальлек режимын үтәү турында йөкләмә-килешүләр (5 нче кушымта).

Әлеге Регламентның 2.8 пуктында каралган документларны кабул итүдән баш тартырлык нигезләр булган очракта, Бүлек белгече гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында гариза бирүчегә хәбәр итә һәм, тапшырылган документларда ачыкланган җитешсезлекләр эчтәлеген язма рәвештә аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

Файдаланучының уку залында эшләү срогын озайту турында гаризасы кергән очракта, 3.4.4. пунктчада каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза бирүче килгән көнне 15 минут эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, бирелгән анкеталар һәм персональ белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгы һәм конфиденциальлек режимын үтәү турында йөкләмә-килешүләр яисә гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.4.2. Гариза бирүче, аның законлы вәкилләре, аны озата йөрүче затлар Тәртип белән танышалар, түбәндәгеләрне тутыралар: файдаланучы – файдйланучы анкетасын, аның законлы вәкилләре, аны озата йөрүче затлар анкета, анда

түбәндәгеләр күрсәтелә: фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булса), туган датасы, гражданлыгы, эш (уку) урыны һәм вазыйфасы (булса), яшәү (тору) урыны буенча теркәү адресы, фактта яшәү адресы, контакт телефонының номеры (булса), электрон почтасы адресы (булса), шәхесен таныклаучы документы төре, сериясе, номеры һәм датасы, шулай ук документны биргән орган, озата йөрүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булса), персональ белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгы һәм конфиденциальлек режимын үтәү турында йөкләмә-килешүләр, аларны Бүлек белгечәнә тапшыралар.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар файдаланучыдан анкета алган мизгелдән 15 минут эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: файдаланучының, аның законлы вәкилләренең, аны озата йөрүче затларның тутырылган анкеталары, персональ белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгы һәм конфиденциальлек режимын үтәү турында Бүлек белгечәнә тапшырылган йөкләмә-килешүләр.

3.4.3. Бүлек белгече:

анкеталарны тутыруның дөреслеген, персональ белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгы һәм конфиденциальлек режимын үтәү турында Бүлек белгечәнә тапшырылган йөкләмә-килешүләр булу-булмавын тикшерә һәм гариза бирүчегә документларны, файдалану фонды күчермәләрен, описьларны бирүгә заказ (таләп) бланкын (алга таба – заказ бланкын) бирә (6 нчы кушымта).

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар файдаланучыдан анкета алган мизгелдән 15 минут эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган заказ бланкы.

3.4.4. Гариза бирүче заказ бланкын тутыра һәм Бүлек белгечәнә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар заказ бланкын алган мизгелдән 15 минут эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: тутырылган һәм Бүлек белгечәнә тапшырылган заказ бланкы.

3.4.5. Бүлек белгече заказ бланкын алганнан соң түбәндәгеләрне башкара:

тутыру дөреслеген тикшерә;

описьлар җыелмасын, саклагычтан архив документлары сайланышын әзерли;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8. һәм 2.9. пунктларында каралган нигезләр булу-булмауны тикшерә;

әлеге Тәртипнең 3.2, 3.3, 3.4, 3.5 пунктларында каралган чикләнгән файдаланудагы эшләр, документлар, аларга карата белешмә-эзләү чаралары, басма нәширлекләр булу-булмауны тикшерә;

бирелүче документлар халәтен тикшерә;

заказ бланкында бирелүче документлар атамалары һәм саны графасын тутыра.

Әлеге Тәртипнең 3.2, 3.3, 3.4, 3.5 пунктларында каралган чикләнгән файдаланудагы эшләр, документлар, аларга карата белешмә-эзләү чаралары, басма нәширлекләр булган очракта, гариза бирүчедән чикләнгән файдаланудагы эшләр, документлар, аларга карата белешмә-эзләү чаралары, басма нәширлекләр алу өчен нигез булган документларны соратып ала.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр яисә чикләнгән файдаланудагы эшләр, документлар, аларга карата белешмә-эзләү чаралары, басма нәширлекләр алу өчен нигез булырлык документлар булган очракта, Бүлек белгече:

гариза бирүчегә, сәбәбен күрсәтеп, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында телдән хәбәр итә;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуны гражданнар гаризаларын һәм оешмаларның хатларын теркәү журналында терки.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар заказ бланкы алынган мизгелдән 15 минут эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: файдаланучыга эшләү өчен бирелгән документлар яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту.

3.5. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтү.

КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтелми.

3.6. Техник хаталарны төзәтү.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Башкарма комитет тарафыннан гариза бирүчегә бирелмәгән документ булуга бәйле рәвештә, техник хаталарны төзәтү гамәлгә ашырылмый.»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаятьләр бирү тәртибе» бүлегендә:

5.1 пунктта:

5 пунктчада «Россия Федерациясенең» сүзләреннән соң «законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары» сүзләрен өстәргә. «_______муниципаль берәмлекнең» сүзләрен «муниципаль хокукый актлар» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктчага «җибәрелгән» сүзләре алдыннан «алар тарафыннан» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 8, 9 пунктчалар өстәргә:

«8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогы һәм тәртибе бозылган;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору нигезләре федераль законнар яисә Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары яисә бүтән норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтү туктатып торылган»;

5.2. пунктның беренче абзацында «шикаять» сүзе алдыннан «дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәткәрнең карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) карата» сүзләрен өстәргә;

5.2. пунктның икенче абзацында «http://uslugi.tatar.ru» сүзләрен «http://uslugi.tatarstan.ru» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 5.7. пункт өстәргә: «Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берәрсе кабул ителә:

1) шикаятьне канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән төгәлсезлекләрне һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының

норматив хокукый актлары белән, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;


2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла»;

5.8. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу һәм җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләр тапшырылган хезмәткәр кичекмәстән булган материалларны прокуратура органнарына җибәрә;».

2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең өзлеклелеге
блок-схемасы


Бүлек белгече. Консультация.
Гариза бирүче Бүлеккә гариза бирә
Тапшырылган гариза
Бүлек белгече шәхесне билгели, гаризаны терки һәм танышу өчен гариза бирүчегә, аның законлы вәкиленә, аны озата йөрүче затларга Тәртип һәм тутыру өчен анкета, персональ белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгы һәм конфиденциальлек режимын үтәү турында йөкләмә-килешүләр бирә
Бирелгән Тәртип, анкеталар һәм йөкләмә-килешүләр
Гариза бирүче, аның законлы вәкиле, аны озата йөрүче затлар Тәртип белән танышалар һәм анкеталар тутыралар, йөкләмә-килешүне имзалыйлар
Тутырылган анкеталар һәм имзаланган йөкләмә-килешүләр
Бүлек белгече анкетаны тутыру дөреслеген, йөкләмә-килешүдә имзалар булу-булмауны, соратып алынучы архив документлары булу-булмауны тикшерә
Тикшерү нәтиҗәләренә бәйле рәвештә карар кабул итү
Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен 2.9 пункт белән каралган нигезләр булмау
Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен 2.9 пункт белән каралган нигезләр булу
Бүлек белгече гариза бирүчегә баш тарту сәбәбен хәбәр итә
Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итүләр
Бүлек белгече заказ бланкы бирә
Бирелгән заказ бланкы
Гариза бирүче заказ бланкын тутыра һәм Бүлек белгеченә тапшыра
Тутырылган заказ бланкы
Бүлек белгече тутыру дөреслеген тикшерә, документлар сайлап ала һәм бирә
Өйрәнү өчен бирелгән документлар

»;

3 нче кушымтаның үз көчен югалтуын танырга.